| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>БАГАЕВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>БАГАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10 нчы ноябрь, 2022 ел Багай ав. № 3

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районы Багай авыл җирлегенең Салтыган авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 25.1,56 маддәләре,«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 23 ноябренә 11 сәгать 00 минутка, Салтыган авылы, Үзәк урамы, 52 нче йорт адресы буенча урнашкан кибет янында, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлегең Салтыган торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***беренче этабын*** билгеләргә.

2. 2022 елның 23 ноябренә 13 сәгать 00 минутка , Салтыган авыл клубы бинасында: Салтыган авылы, Үзәк урамы, 48а йорт, адресы буенча урнашкан, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлегең Салтыган торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***икенче этабын*** билгеләргә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны буенча Багай авыл җирлеге Салтыган торак пункт территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

*а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:*

- материаллар сатып алып, урамнарны яктыртуны ремонтлау;
- материаллар сатып алып, чишмәләрне, буаларны ремонтлау, чистарту һәм төзекләндерү;
- авыл җирлегендә торак пунктлардагы чүплекләр территорияләрен чистарту;

*б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:*

- су суырту башняны, һәм суүкәргеч челтәрләрен карап тоту;
- су башнясын лицензияләү буенча әзерлек эшләре, тирә ягы койма белән тотып алу, һәм башка эшләр;

*в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:*

- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

*г) беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:*

- янгын сүндерү ДПО карап тоту.»

« РИЗА» «КАРШЫ»

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Республикасы Кайбыч муниципаль районының
Багай авыл җирлеге Башлыгы Р.Ф.Кузнецова